**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 21 март № 170

г. Казань

«Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Кама Тамагы муниципаль районындагы «Богородский рай» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе структурасын оптимальләштерү турында

Татарстан Республикасының социаль яклау тармагы инфраструктурасын оптимальләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Кама Тамагы муниципаль районындагы «Богородский рай» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенең (алга таба – «Богородский рай» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге) 20 койка-урынлы социаль-тернәкләндерү бүлеген ябу турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына:

«Богородский рай» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге әлеге учреждениенең структурасын оптимальләштерү чараларын үткәргәндә хезмәткәрләргә гарантияләр һәм компенсацияләр бирүне Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә тәэмин итәргә;

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә «Богородский рай» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәгенә оператив идарә хокукында беркетелгән Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтенең аерым төрләрен алга таба файдалану турында тәкъдимнәрне «Богородский рай» халыкка социаль хезмәт күрсәтү

комплекслы үзәгенә даими вакыты чикләнмәгән файдалану хокукында беркетелгән әлеге мөлкәт һәм җир кишәрлекләре исемлеге белән кертергә;

тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы» ведомствосы буенча «Богородский рай» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге тарафыннан дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанслар белән тәэмин итүгә каралган чыгымнар өлешендә күздә тотылган акча чикләрендә «Богородский рай» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге структурасын оптимальләштерү белән бәйле чараларны үткәрүгә чыгымнарны финанслауны тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына 60 көн эчендә элек «Богородский рай» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәгенә беркетелгән Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен һәм 120 көн эчендә элек «Богородский рай» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәгенә беркетелгән җир кишәрлекләрен Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы биргән мөлкәт исемлеге нигезендә законнарда билгеләнгән тәртиптә бирүне тәэмин итәргә.

4. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә әлеге карарның 2 нче һәм 3 нче пунктларында күрсәтелгән барлык чаралар тәмамланганнан соң эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2017 елга Татарстан Республикасы социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында» 2016 ел, 18 ноябрь, 849 нчы карарына тиешле үзгәрешләрне кертү хакында тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы<br>
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2017\170.doc